# Сөләймановлар кыры





Техника буенча бригадир ярдәмчесенең, билгеле инде, төп эше паркта. Иртәгесен тракторларны караткөйләп басуга озата да, әзрәк тын ала. Җәмил Сөләйманов бушануга улын — Фәнилне исенә төшерде: эшләре ничек бара икән?

Фәнил агрегаты шикәр чөгендере басуында. Бергә чәчкән участокларыннан уңышны ул башкалар белән ала — эти кешене җаен бригадир ярдәмчесе итеп күчерделәр. Әмма дистә еллар бергә хезмәт куйган эти кеше башлаган эшенең ахыры белән кызыксынмавы мөмкин хәлме соң!

...Сөләймановлар, гомумән, җиргә береккән кешеләр. Җәмил үзе авылда туган, үскән, җирдән аерылуны күз алдына да китерми. Бу аның канына сеңгән. Авылдагы һәртөрле шөгыль аның күңеленә якын. Беркайчан эшнең җиңелен, файдалысын санап тормады, кая кушсалар — шунда барды. Тракторга утыруы да шулай килеп чыкты: чакырдылар, үтенделәр һәм ул каршы килмәде.

Дистә еллар элек, тәҗрибә туплагач, шикәр чөгендере игү звеносына беркеттеләр. Өлкән Сөләйманов бусына да теләп алынды, күңел биреп эшләде басуда. Буш чакларында, җае чыккан саен, улы Фәнилне үзе белән иярткә иде. Ул чакта мәктәптә укып йөргән үсмер әрсез, кызыксынучан булып чыкты: әтисен игътибар белән күзәтә, кирәк икән булыша: аны ял иттерергә дә, руль артына алмашка утырырга да һәрчак әзер. Эти кеше боларны күреп эчтән сөенә торган иде.

Фәнил мәктәптән соң техника паркына эшкә килде. Эти кеше үзенең йогынтысы бушка китмәгәнлеген күреп шатланды. Шулай да күңелгә эчке бер борчу тынгы бирмәде. Яшьләрнең төрлесе бар бит авылда. Бер ишесе солдатка киткәнче паркта техника тирәсендә көн үтсенгә буталып йөри дә, армиядән соң — син күр дә, мин күр. Шуңа күрә улына гел күзколак булды, кыенлык, тоткарлык килеп чыкса, эшне җайга салышырга үзе алынды.

Фәнил үзе дә кушканны гына көтеп тормый, һәр эшкә тәвәккәләп керешә. Моны күреп өлкән Сөләймановларның да күңеле үсә, улына ышанычы арта барды.

Эти кеше дөрес сиземләгән булып чыкты, улы армиягә киткәч тә хат саен күңеле авылга тартуын сиздерә килде. Хезмәт срогын тутырып кайткач та, кала ягына омтылмады.

Җәмил аны үзе эшләгән шикәр чөгендере игү звеносына сорап алды. Басуда гел янәшә эшләделәр: берсе культивацияләсә, икенчесенең агрегаты чөгендер чәчте яисә җирне кабат тырмалый барды. Рәт арасын эшкәрткәндә еш кына агрегатлары басуны янәшә иңләде. Ярыша-ярыша эшләделәр. Шулай дигәч тә, гектар артыннан куып түгел, җиренә җиткереп, сыйфатка зыян китермичә, әлбәттә.

Быел да бригададагы 50 гектар чөгендерне игүгә бергә керештеләр. Тик эти кешене озакламый, алда әйтелгәнчә, бригадир ярдәмчесе итеп күчерделәр. Ләкин бу эшкә зыян китермәде. Фәнил шактый еллар бергә чөгендер иккәнгә һәр технологик чараны, кем әйтмешли, инәсеннән алып җебенә кадәр белә, үзе дә оста башкара килде.

Басудан буш чакларында да кул кушырып утырмый егет, уракка хәзерләнде. Комбайнын сәгать механизмы кебек төгәл ремонтлап чыкты басуга. Һәм 300 гектардан артык мәйданда игеннәрне тезем нәргә салды. Бу колхозда иң югары күрсәткеч.

Хәзер авылда икенче урак өсте, шикәр чөгендере уңышын җыялар. Фәнил тракторына БМ-6 тагып чөгендер сабагын урдыра. Ә аның артыннан ук диярлек Нәят Ахунҗановның РКС-6 комбайны чөгендерне казытып бара. Нәят тә уңган механизатор, басуда сыната торганнардан түгел. Чөгендер игүче хатын-кызлар Зөһрә һәм Гөлсирә Вафина, Гамбәр Хәйруллина, Мөслимә Галимова, Минҗиһан Гыйниятуллина һәм башкалар казыган чөгендерне чистартып кагатларга сала баралар. Һава шартлары иркенләргә ирек бирми. Шуңа күрә уңыш җыюда катнашучы һәркем аяз көнне, сәгатьләрне нәтиҗәле файдаланып калу өчен тырыша.

Өлкән Сөләйманов, бу эшләргә турыдан-туры кагылышы булмаса да, басудагы чөгендерчеләр хезмәтен оештыру, аны тәэмин итү мәшәкатьләре белән мәшгуль. Шулай булмый ни, аларның, Сөләймановларның үз кыры ич ул басу.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**

«Знамя Октября» колхозы.

**Рәсемнәрдә: аталы-уллы Сөләймановлар.**

***Педагог уйланулары***

# Гөлбакча булсын урамнар

Язмыш шулай хәл иткән булып чыкты ки, миңа союзның төрле почмакларында булу белән бергәттән, Көнчыгыш Европа илләренең байтагында — Венгрия, Австрия, Чехо-Словакия, Болгария һәм Германия җирләрендә дә булырга туры килде. Ул илләрдәге халыкның тормыш-көнкүреше, культурасы һәм башка мәсьәләләр белән дә кызыксындым. Шулар турында бер фикеремне газета укучылар белән дә уртаклашасым килә.

Мине иң гаҗәпләндергәне андагы авыл халкының тормышы. Анда бездәге кебек таптап-изеп бетерелгән урамнарны күрә алмыйсың. Җәйге чорда бөтен тирә-юнь яшеллек эчендә утыра. Йорттан урамга чыга торган аллея, сукмак, юлның ике ягына куак утыртып чыкканнар. Алары да бездәге шикелле яшеллек өчен генә үсә торганнары түгел, җиләк-җимеш куаклары.

Олы юл буена да шундый ук җимеш бирүчән агачлар — алма, чия һәм башкалар утыртылган. Беркинди койма, киртә дә юк, мылтык аскан сакчы да йөрми. Ул агачларны сындыручы, җимешен өзүче дә юк.

Шуларны баштан кичерәм һәм үзебездә мәсьәләнең куелышы белән чагыштырам. Бездә алма бакчасы үстерергә теләүче булса алдан кеше керә алмаслык койма булдыру хәстәрен күрә, бозау хәтле эт алып җибәрә.

Яшерен-батырын түгел, әхлак һәм культура ягыннан да без алардан калышабыз әле. Балаларга коллективизм, социалистик милекне саклау турында мәктәптә вәгазь укыйбыз, ә ул күршенең яшелчә бакчасындагы җимешенә кызыга. Монда баланы да гаепләп булмый, үзләрендә үстерелмәгән яшелчә, җимешне татып карарга теләве бик табигый.

Бу очракта озын-озакка сузылган педагогик әңгәмә корып вакыт үткәргәнче, практик хәрәкәт зарури. Ягъни яшелчә, җиләк-җимешне үзең үстерү турындагы фикерне бала аңына сеңдерү кирәк.

Бу уңайдан үткәнебезгә күз салыйк әле. Элек-электән бакчачылык белән шөгыльләнмәгән безнең халык. Башта аның файдасына төшенмәгән, надан булган. Бөек Ватан сугышыннан соң һәр төп алмагачка налог сала башлагач, утыртылган агачларны да кисте халык. Җитмешенче елларда җиләк-җимешне күп йортлар утырта башлаган иде, 1979 елдагы чамадан тыш салкын үсентеләрнең күбесен туңдырды — корыдылар.

Бакча тотуның файдасы күп төрле. Гаиләнең буш вакытын сарыф итүче шөгыль булу өстенә балаларга хезмәткә өйрәтү күнекмәләре дә бирә. Материаль ягын да исәпкә алу мөһим: гаиләне яшелчә белән тәэмин итүгә өстәмә чыганак. Балалар өчен исә үзе хезмәт куйган участокның җимешен тату аеруча кадерле: эшләгәч аш тәмле була. Шуны да әйтик, җитмешенче елларда бакча җимеше — алма, чияне көзен кая куеп бетерергә мөмкин түгел иде. Аңлашыла ки, андый чакта җимеш арзан да була. Һәм тагын бер ягы — һәр йортта бакча булганда кешенекенә күз атучы, нәфесен сузучы да калмый, әхлак тәрбиясе ягыннан да гаять әһәмиятле ул. Бүген базар экономикасына күчкәндә бу бигрәк тә файда. Суган үстерү моны исбатлады инде. Башка төр яшелчәгә дә мәйдан киңәйсен иде.

Соңгы елларда безнең Яңа Иглай авыл Советы территориясендә бу юнәлештә уңай якка хәрәкәт башланды шикелле. Ике терлекчелек фермасы янында алмагач куаклары утыртылды. Мәчет тирә-юнен бакча итү планнары бар. Йорт яны бакчаларын торгызу, киңәйтергә яисә аны булдырырга теләүчеләр байтак. Бу уңайдан җиләк-җимеш питомнигы, совхоз администрациясенең халыкны үсентеләр белән тәэмин итүдә нәтиҗәле булышулары сорыйсы килә. Анылларны элеккечә пропаганда өчен генә түгел, туры мәгъсендә гөлбакча итсәк, үз-үзебезнең яшелчә һәм җиләк-җимешкә ихтыяҗны канәгатьләндерер, халыкта, аеруча балаларда, бу төр байлыкка сак караш тәрбияләүгә ирешер идек.

**Т. ГОБӘЙДУЛЛИН.**

Яңа Иәлай авылы.



**Шофер кеше, җырда әйтелгәнчә, гел юлларга гашыйк. Һәм бу «Путь к коммунизму» колхозының автомобиль йөртүчесе Анатолий Гаврилович Албутовка да тулысынча тәнгәл килә: хезмәтен ярата. Ә хезмәте гел юлда сәяхәттән тора. Албутов аннан еллар буе аерыла алмый эшли.**

**Анатолий Гаврилович бу хезмәтенә сигез еллар элек керешкән иде. Төрле машинада эшләде, хәзер исә үзбушаткыч автомобильне йөртә. Урак кизренке чакта ындырга ашлык ташыды, аны амбарга бушатуга да өлеш кертте.**

**Рәсемдә: «Путь к коммунизму» колхозы шоферы А. Г. Албутов.**

**В. Никонорова фотосы.**

# СӘЛАМӘТ АКЫЛ БЕЛӘН ХӘЛ ИТИК

Илебез авыр хәлдә. Уңай якка таба үзгәрешләрне һәркем түземсезлек белән көтә. Ләкин бер сорау борчый. Тынычлыкны саклап кала алырбызмы? Бигрәк башбаштаклык китте бит, бер генә тәртип тә калмады. Шөкер, ач яшәмибез һәм киенмичә дә тормыйбыз. Ләкин кибетләрнең бушап калуы, күз явын алырлык затлы товарларны спекулянтларның нинди аулак урын бар, шунда чыгарып бәясен өчләтә арттырып сатуларына йөрәк әрнемиме? 60—70 тиенлек бер әчмуха чәйне 5 әр сумга ала башласаң...Каян җиткерергә ди ул безнең кебек югары хезмәт хакы алмаган эшчеләргә акчаны? Кемнәрдер һинд чәе эчә, ә без грузинын да күрә алмыйбыз... Чәе ярар, бер булмаса бер сатарлар. Ә шикәр комын ничек юнәтергә? Менә без, мәсәлән, үзебез кәне буена типографиядә эштә, ә бу вакытта Норлат кибетләрендә рәхәтләнеп шикәр белән сәүдә итеп яталар. Шунысы да бар, бөтен кибеттә дә түгел әле. Нибары бер кибеттә. Күпчелек очракта ул нефтьчеләр кибетенә туры килә. Дөрес, без инде эшне калдырып бер бардык, һәм ниләр күрдек диегез!.. Борма-борма озын чират сузылып киткән, аяк басар урын юк. Этеш-төртеш, кычкырыш, кемнәрдер чиратсыз алалар. Кибет эчендә тынчу, сулар һава юк. Талонның кулда була торып шул шикәр комын да тыныч кына ала алмагач, ничек кәефең кырылмасын ди. Анысы ярар әле, ул ай дәвамында бөтенләй дә булмаска мөмкин. Сатучылар я бәясе күтәрелгәнне көтеп яталар, я кемнәрдер боерыгы буенча сатарга кушмаганнар. Шулай булгач, кая соң гаделлек, дөреслек? Шикәр комын яшертен, кыйммәт бәягә сатучыларга карата да тиешле контроль булдырырга вакыт. «Кемнең кулында, шуның авызында» принцибына чик куярга вакыттыр. Кайсына гына тотынсаң да шул ук хәл. Талонга ни аракы, ни дөге ярмасы, ни конфетын, печеньесын алып булмый. Ни өчен күрше өлкәләрдәге шикелле бездә дә товарларга визит карточкасы системасы кертелми. Хатын-кыз һәм ир-ат киемнәрен болай гына беркайчан да сатып ала алганыбыз юк, гадәттә ул әйберләр сәүдә базаларына кайтсалар да...

Договор бәясе дигән нәрсәне дә аңлап бетермибез. Кемнәр юл куя аның үтәлүенә? Бер консерв банкасын 5 әр сумга сатып файда күрүче предприятиеләр өчен куаныч булса, соңгы акчаны чыгарып бирү безгә бик кызганыч.

Кооператорлар турында да сүз кузгатасыбыз килә. «Иверия» кооперативының халыкка хезмәт күрсәтүеннән кемнәр генә канәгать калыр икән? Иртән автовокзал каршына җиңел машина килеп туктый, аннан «Иверия»дә эш башлана. Пилмән, салкынайтылган эчемлек, балга катырылган суыра торган конфетлардан кала биредә берни дә юк. Шул да булдымы хезмәт күрсәтү? Рәхәтләнеп бер утырып тамак ялгап алып та булмагач...Монда һәммәсе бары тик шул акчага гына корылган. Акчаң бир дә, алар үргән «ятьмәгә кер».

Талон системасындагы тәртипсезлекләр аеруча борчый күңелебезне. Кемнәрдер шуннан да файда күрәләр, 5 әр сумга саталар бер-бер аракы талонын. Ник учетка алмыйлар икән талоннарны? Мондый хәл дә килеп чыкмас иде.

Кыскасы, җәмгыятебездә уңай якка үзгәрешләр көтәбез. Ул көн тизрәк килеп җитсен иде. Тынычлык, муллык һәм сәламәтлеккә берни дә җитә алмый. Бу мәсьәләләрнең сәламәт акыл белән хәл ителүен телибез.

**М. ЗЫЯТДИНОВА,**
**Н. КВАШНИНА,**
**А. СИТДИКОВА һәм башкалар.**
Норлат шәһәре.

## *Яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр*

**Норлат элеваторының ярдәмче хуҗалыгы 1987 елда оешкан иде. Мөгезле эре терлекләрне Хафизов исемендәге колхоздан арендага җир һәм бина алып, ә дуңгызларны тимер юл янындагы аерым участокта асрарга булдылар. Көткән өметләр акланды. Бер яктан арендачылар эштә әйбәт күрсәткечләргә ирешсәләр, икенче яктан эшчеләрне ит белән тәэмин итеп тору мөмкинлеге туды. Агымдагы елның сигез аенда арендачылар көче белән 4 айдан зуррак булган мөгезле эре терлекләрдән 83 центнер, симертү группасындагы 150 баш дуңгыздан 44 центнер продукт алынды. Мондый куанычлы нәтиҗәләргә ирешүдә ярдәмче хуҗалык эшчеләре Гали Гомәрович Гыйззәтов, Антонида Никитична Долгова, Минсәлим Миннәхмәтович Ногманов та үзләреннән өлеш керттеләр.**



**Рәсемдә безнең фотокорреспондент Н. Азизов арендачылар М. М. Ногманов, А. Н. Долгова һәм Г. Г. Гыйззәтовны терлекчеләр слетында фотога төшереп алган.**

# Кагыйдә бозу—яхшыга илтми

Районда 1 нче августтан бирле дәүләт автоинспекциясе тарафыннан юл хәрәкәтенә көчәйтелгән күзәтчелек алып барыла. Айдан артык вакыт эчендә юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуның 500 дән артыграк очрагы теркәлде. Һәм шуның 180 ендә транспорт хуҗалары аек булмаган хәлдә идарә итүләре өчен гаепләнәләр.

Алар арасында «Алга» колхозыннан Җәүдәт Гыйммранов, Рәшит Фәрдиев, Рамил Вәлиев, «Комбайн»нан—Госман Шакирвәлиев, Ислам Мәхмүтов, Рөстәм Сәмирханов, Александр Мурасов, Синдряков исемендәге колхоздан Евгений Емельянов, Сергей Пигасов, Валерий Григорьев, Александр Екамасов һәм башкалар бар. Шул рәвешле «салган» килеш транспорт йөртү буенча «алдынгылык»ны Иске Чаллы һәм Яңа Әмзә егетләре беркемгә дә бирмиләр.

Исерек килеш транспорт йөрткәндә икенче кабат эләгүчеләр дә 40 тан артык кеше. Бу яклап «Норлатнефть» НГДУ сы идарәсеннән юл участогы, Синдряков исемендәге колхоз һәм «Рассвет» совхозы шоферлары аеруча «активлар».

Әлеге кагыйдә бозуларның турыдан-туры нәтиҗәсе буларак, бәрелү, үлем-җитем очраклары да күп теркәлде. Җәйге айларда барысы 42 юл-транспорт һәлакәте булып, 8 кешенең гомере өзелде, 28 кеше җәрәхәт алды.

20 июльдә Мамыкта яшәүче А. Лапшов исерек килеш транспорт белән идарә итеп юлдагы мотоциклны бәрдерә. Нәтиҗәдә, мотоцикл коляскасында утырган В. Ульянин шифаханәдә җан бирә.

27 июльдә Н. Нуркин шулай ук эчкән килеш мотоциклның тизлеген арттыра һәм ава. Авыр яраланган «батыр»ны шифаханәгә китерәләр.

26 июльдә И. Шәйдуллин «ЗИЛ-131» машинасындагы транспортны куып узу кагыйдәсен боза. Һәм нәтиҗәдә мотороллерда баручы Ф. Ильмухинның гомере өзелә.

18 августта «Үрнәк» колхозыннан Н. Сәлахов эчкән килеш «ГАЗ-53» автомашинасы белән юлның сул ягына чыга һәм мотоцикл белән бәрелешә. Мотоцикл хуҗасының башы авыр җәрәхәтләнә.

Кыскасы, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу һич тә яхшылыкка илтми. Югарыда сөйләнгәннәр—шуның ачык мисалы.

**Н. ГАЙНЕТДИНОВ,**
дәүләт автоинспекциясенең юл-патруль службасы өлкән инспекторы, милиция лейтенанты.

# Бәхетсезлек булмасын дисәк



Авыл электр бүлгечләренең озынлыгы тармаклары белән бергә 50—80 километр тәшкил итә. Электр производствосы аның элементлары арасында турыдан-туры элемтә булуы белән үзенчәлекле. Ә инде энергияне эшләп чыгару, үткәрү һәм бүлү процессы бозылу тулы районны электр белән тәэмин итүдә өзеклек тудыра, промышленность предприятиеләренең һәм колхоз-совхозларның эш режимнары бозылуга китерә, көнкүрештә дә кыенлыклар китереп чыгара.

СССР Министрлар Советы һәм РСФСРның Югары Советы Президиумы карары белән «Электр челтәрләренең бозылуына китерүчеләрне административ җаваплылыкка тарту турында» Указ расланган. Электр линияләренең саклануын һәм нормаль эшләвен тәэмин итү максатында махсус кагыйдәләр каралган:

а) торак пунктлардан үтүче һәм параллель турылар белән билгеләнгән һава электр үткәргеч линияләре арасы кырый үткәргечтән көчәнеше 20 киловольтлы линия өчен 10 метр, 35 киловольтлы өчен 15 метр, 110 киловольтлы өчен 20 метр ераклыкта булырга тиеш.

б) һава электр тапшыру линияләре белән биналар, корылмаларның өске өлешләре арасының 20 киловольт көчәнешле линия өчен 2 метр, 35 киловольт һәм 110 киловольт өчен 4 метрдан ким булмавы зарур.

в) бәхетсезлек очраклары килеп чыкмасын өчен, электрүткәргеч линияләрен файдаланучы оешмаларның язма рөхсәтеннән башка төрле корылмалар төзү, шартлату эшләре алып бару катгый тыела.

г) электрүткәргечнең һава линияләре астында биеклеге 3 метрдан арткан машиналарның йөрүе тыела.

Югарыдагы Указда каралган кагыйдәләрне үтәмәү аркасында электр челтәренең, подстанцияләрнең бозылуына сәбәпче булган аерым гражданнар һәм җаваплы кешеләр штрафка тартылалар. Аларның эше район яки шәһәр Советлары башкарма комитетларының административ комиссияләрендә карала. Бу комиссия каравына нигез булып үзенең карамагында электр челтәре булган оешманың вәкаләтле вәкиле яисә урындагы кеше төзегән акт тора. Шунысы да бар, штраф гаепле кешене билгеләнгән тәртиптә китерелгән материаль зыянны түләүдән азат итми. Безнең район колхоз һәм совхозларында да быелның беренче яртыеллыгында электр белән тәэмин итүдә өзеклекләр килеп чыкты.

Мәсәлән, 26 июльдә «Чирмешән» колхозында салам өйгеч белән электрәп югары вольтлы һава электр үткәргече өзелә. Нәтиҗәдә салам эскерте яна.

19 июльдә Гәйтән авылы янында билгесез транспорт электр үткәргечен өзеп китә.

Бу уңайдан хуҗалык җитәкчеләренең кыр эшләре вакытында механизаторларга, шоферларга электр челтәрләрен саклау кагыйдәләрен аңлату һәм аның мәҗбүри үтәлешен тәэмин итүе сорала.

Биредә тагын бер гади электр куркынычсызлыгы кагыйдәсе турында искәртеп үтәбез. Җирдә өзелеп яткан электр чыбыгы янына 8 метрдан да якынрак килергә ярамый. Бу турыда кичекмәстән 2—25—24 яисә 2—13—98 номеры буенча район электр челтәренә хәбәр итү сорала. Югарыда күрсәтелгән кагыйдәләрне төгәл үтәү күңелсез хәлләрне китереп чыгармаска ярдәм итәчәк.

**Д. ИЩЕРЯКОВ,**
район электр челтәре инженеры.

## *Өстәлләргә—витамин*

**Мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә.**

Быел берләшмәдә беренче ел яшелчә утыртылган иде. Хуҗалык ашханәсенә зур ярдәм булды ул: җәен кыяр-помидорына кинәнделәр, инде кәбестә, кишер, кызыл чөгендергә рәхәтләнәләр. Ашханәдә тукланучылар да моннан канәгать: аш алдыннан яшелчә салаты ай-һай яхшы витамин!

**«Кондырча» колхозы.**

Хуҗалык яшелчә үстерү белән берничә ел рәттән шөгыльләнә инде. Һәр елны продукциягә сорау зур була. Быел да иртә өлгерә торган кәбестәне алырга теләүчеләр бик күп иде. Әмма хуҗалык үзенчә хәл кылды: продукция белән иң элек балалар бакчаларын тәэмин итте. Чөнки биредә иң чиста, нитратсыз кәбестә үстерелә.

**С. НУРУЛЛИНА.**

